**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче Иске Элмәле һәм Яңа Элмәле торак пунктларында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**№1** **15.10.2021 ел**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 15 октябрендә түбәндәге мәсьәләләр буенча узган халык җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены карары төзелде:

2022 елда Яңа Элмәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җәйге һәм кышкы чорда юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, элмә һәм тагылма җиһазлар сатып алуга, тракторчыга хезмәт күрсәтүгә түләү) Яңа Элмәле һәм Иске Элмәле торак пунктларында;
- Яңа Элмәле һәм Иске Элмәле авылларында урамнарны яктырту, монтажлау, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- юл билгеләре сатып алу:
- «Авыл территорияләренең заманча йөзе» республика программасында катнашу өчен проект-смета документларын, дәүләт экспертизасын әзерләү һәм түләү:
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Элмәле авылында Сөлчә елгасы аша җәяүлеләр күперен капиталь ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 839 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 507 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында 507 катнашучы тавыш бирде; «ЮК» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге составына керүче Иске Элмәле һәм Яңа Элмәле авылы торак пунктларында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип таныргa.

2. Киләсе мәсьәлә буенча:

2022 елда Яңа Элмәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

- җәйге һәм кышкы чорда юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, элмә һәм тагылма җиһазлар сатып алуга, тракторчыга хезмәт күрсәтүгә түләү) Яңа Элмәле һәм Иске Элмәле торак пунктларында;

- Яңа Элмәле һәм Иске Элмәле авылларында урамнарны яктырту, монтажлау, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- юл билгеләре сатып алу:

- «Авыл территорияләренең заманча йөзе» республика программасында катнашу өчен проект-смета документларын, дәүләт экспертизасын әзерләү һәм түләү:

- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Элмәле авылында Сөлчә елгасы аша җәяүлеләр күперен капиталь ремонтлау, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу – карар кабул ителгән дип таныргa.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Иске Элмәле авылы, Үзәк урамы, 10 һәм Яңа Элмәле авылы, Ключевая урамы, 15. Татарстан Републикасы Чирмешән муниципаль районы рәсми сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы** **Мельников В.П.**